| | |
|---|---|
| ГЛАВА ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.11. 2023 ел № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ**:

1. 2023 елның 28 ноябрендә 14.00сәг. үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнар җыенын билгеләргә. Гражданнар җыены уздыру урыны итеп Тойгуҗа авылы Үзәк урам 48 йорт адресы буенча урнашкан Тойгуҗа авыл мәдәният йортын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

"Сез 2024 елда җыелган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- скважина өчен су насосы сатып алу;
- сууткәргеч бикне һәм янгын гидрантларын комплектта сатып алу;
- сууткәргеч бикне һәм янгын гидрантлары урнаштыру;
- авыл җирлеге территориясендә үлән чабу;
- юлларны кардан чистарту;
- узган елларның калдыкларын янгын гидрантларын урнаштыруга җибәрергә».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сафин